КИҢӘШЛӘНГӘН
**Казан шәһәре Совет районының «178 нче номерлы катнаш төрдәге билингваль балалар бакчасы» профком рәисе**
_________________ Загидуллина А.А.
«29» август 2022 г.

РАСЛЫЙМ
**Казан шәһәре Совет районының «178 нче номерлы катнаш төрдәге билингваль балалар бакчасы» мөдире**
_________________ Воронцова А.О.
«29» август 2022г.

Педагогик киңәшмәдә каралган һәм расланган.
Беркетмә № 31.2 . 2022 ел.

# Казан шәһәре Совет районының муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениясе “178 нче номерлы катнаш төрдәге билингваль балалар бакчасы”ның татар теленә өйрәтүче тәрбияченең ана теленнән эш программасы.

## 2022-2023 нче уку елы

Мәктәпкәчә белем бирү Федераль дәүләт белем стандартларын күздә тотып,
укыту методик комплектларга нигезләнеп төзелде.

Әзерләде: Минкашева Л.С.

Казан 2022 ел

**ЭЧТӘЛЕК**
**Кереш сүз**

1. **Максатчан бүлек**

1.1 Программаның максаты һәм бурычлары

1.2 Программа принциплары

1.3 Сөйләм үстерү методикасы

1.4 Балага үсеш юнәлешләре буенча белем бирү (биш белем өлкәсендә)

1.5 Программаны тормышка ашыруда төрле технологияләр, формалар, алымнар, методлар һәм чаралар.

**2 Эчтәлекле бүлек**

2.1 Беренче кечкенәләр төркеме “Туган телдә сөйләшәбез”. Комплекслы тематик план.

2.2 Икенче кечкенәләр төркеме “Туган телдә сөйләшәбез”. Комплекслы тематик план.

2.3 Программа буенча белем бирү дәрәҗәсен билгеләү.

2.4 Ата – аналар, педагогик коллектив, балалар белән эш. Мәктәп белән бәйләнеш.

**3 Оештыру бүлеге**

3.1 Татар теле кабинетында предметлы-үстерүче тирәлекне оештыру үзенчәлекләре.

3.2 Эш көне бүленеше

3.3 Әдәбият

## Кереш сүз

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законында һәм «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләр саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы»нда мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. Бу - республикабызда эшләп килә торган милли балалар бакчалары өчен кадрлар әзерләү, аларның белемен күтәрү һәм методик ярдәм күрсәтү мәсьәләләре. Әлеге проблемаларның бер өлеше “Туган телдә сөйләшәбез” өйрәтү-методик комплектлары ярдәмендә чишелә. Тәкъдим ителгән әсбап – татар балаларын туган телгә өйрәтү, аларның сөйләмен үстерү буенча методик кулланма. Аның төп максаты ана телендә балаларның дөрес һәм яхшы телдән сөйләмен формалаштыру. Кече яшьтән үк баланың сөйләмен үстерү аның аралашу, танып белү, әхлакый һәм рухи юнәлешләр нигезен билгели.

Ул 2010-2015 елларга мәгариф системасын үстерү Стратегиясе кысаларында балалар бакчаларында балаларга туган тел өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлешен тормышка ашыру максатыннан төзелгән һәм “Туган телдә сөйләшәбез” дип аталган методик әсбап балалар бакчасында беренче кече яшьтәге балалар белән эшләүче тәрбиячеләргә кулланма буларак тәкъдим ителә. “Туган телдә сөйләшәбез” дип исемләнгән методик комплект икенче кече яшьтәгеләр, уртанчылар, зурлар, мәктәпкә хәзерлек төркемнәре өчен дә әзерләнә. Бу комплектның төп максаты балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү булса, төп үзенчәлеге – тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

Туган телдә сөйләшергә өйрәтү гаиләдә башлана һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә дәвам итә. Ул балаларга ана телендә тәрбия һәм белем бирү өчен мөмкинлекләр тудыру, халкыбызның рухи байлыгына, мәдәниятенә якынайту шартларында алып барыла. Мәктәпкәчә учреждениеләр, мәгариф системасының беренче баскычы буларак, нәниләрне туган телгә өйрәтүдә башлангыч роль уйный.

Беренче кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасы мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасыннан аерыла. Балаларны туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү әйләнә-тирә белән таныштыру процессында бара. Шушы үзенчәлекләрне исәпкә алып, кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеге эчтәлеген төзегәндә әйләнә-тирә предметларны һәм күренешләрне танып белүдә нәрсә чыганак булып торуы игътибар үзәгенә алына. Балаларның сөйләмен үстерү “Кроха” программасында (Г.Г. Григорьева, Н.П. Кочетова, Д.В. Сергеева һ.б.) күрсәтелгән түбәндәге эшчәнлек төрләренә нигезләнеп төзелә:

I. Табигый шартларда табигать һәм социаль тирәлек белән турыдан туры таныштыру.

1. Табигатьне (күренешләрне һәм объектларны) күзәтү.
2. Предметлы дөнья белән таныштыру: предметлар һәм кораллар (исеме, сыйфаты, үзлекләре, эш-хәрәкәтләре).
3. Социаль күренешләр (үзең, якын кешеләр, өлкәннәр хезмәт турында күзаллаулар) белән таныштыру.

II. Образлы уенчыклар, пластик художестволы образлар аша тирә-юнь белән белән таныштыру

1. Уенчыклар карау.

2. “Тылсымлы капчык”, “Бу өйдә кем (нәрсә) яши?” дидактик уеннары, курчак белән дидактик уеннар.

3. Уеннар, күңел ачулар, уен-көлкеләр.

4. Йомыш кушулар (индивидуаль һәм кечерәк төркемнәргә бүлеп).

III. Художестволы картиналары аша (живописный, графический художественный образ) (буяулар һәм буяусыз ясалган образлар (графика) әйләнә-тирә белән таныштыру.

1. Өстәлгә куела торган кечкенә картиналарны, китаптагы иллюстрацияләрне, стенадагы картиналарны карау.

2. “Җанлы” кечкенә картиналар белән эшчәнлек.

IV. Нәфис сүз аша әйләнә-тирә белән таныштыру.

1. Матур әдәбият, юаткычлар, шигырьләр, әкиятләр, хикәяләр уку.

2. Тәрбияче белән бергә кыска гади әкиятләрнең эчтәлеген сөйләү.

V. Күрсәтмәлелектән башка тирә-юнь белән таныштыру һәм сөйләм үстерү.

1. Күрсәтмәлелектән башка һәм ситуциядән тыш тәрбияченең сөйләве.

2. Балалар белән әңгәмәләр һәм сөйләшүләр (тәҗрибәдән чыгып, күзәтүләрдән соң).

Методик әсбапта танып белү, коммуникация, матур әдәбият белән таныштыру кебек өч белем бирү өлкәсе карала. Нәниләр эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик планлаштыру нигезендә бара. План ел дәверендә төрле темалар үзләштерүне күздә тота. Болар - “Балалар бакчасы”, “Көз”, “Мин дөньяның бер кешесе”, “Минем әйләнә-тирәм”, “Кыш”, “Яңа ел бәйрәме”, “Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр”, “Халык иҗаты”, “Яз”, “Җәй”. Елга ике тапкыр диагностик методикалар ярдәмендә мониторинг үткәрелә. Мониторинг нәтиҗәләре балаларның персональ карточкаларына языла.

Туган телне өйрәнүгә юнәлдерелгән эшчәнлек конспектлары Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә чыккан “Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы” нигезендә төзелгән. Авторлар эшчәнлек конспектлары язганда үстерелешле өйрәтү, өйрәтү барышында тәрбияләү, фәннилек, эзлеклелек һәм системалылык, аңлаешлылык, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу, гуманлылык, күрсәтмәлелек һ.б. төп педагогик принципларга таяналар. Өйрәтү-тәрбия процессы балаларның “якындагы үсеш зонасында” (Л.С. Выготский) бара. Бу процессны әйдәп баручылар - тәрбиячеләр.

Өченче яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала. Эшчәнлек төрләрендә сөйләм үсешенең *сүзлек эше, сөйләмнең грамматик төзелеше өстендә эш, аваз культурасы тәрбияләү, бәйләнешле сөйләм үстерү, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру* бурычлары хәл ителә.

Балалар белән эшләү процессында *сүзлек эше* зур урын ала. Сүзлек эше- бәйләнешле сөйләм нигезе. Балалар

бакчасында сүзлек эшенең өч бурычы чишелә:

1. Иң беренче чиратта, гомуми кулланылыштагы лексика хисабына (предметларны, аларның төп билгеләрен, сыйфатларын, алар белән эш-хәрәкәтләрен атау) сүзлекне баету.

2. Сүзлеккә төгәллек кертү. Балаларга сүзне әйтү үрнәген бирү, аны һәр бала белән күп тапкыр кабатлау.

3. Сүзлекне активлаштыру.

*Сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыруның* төп шарты – тәрбияченең, өлкәннәрнең грамоталы сөйләме һәм сөйләмнең морфологик, синтаксик ягын, сүзъясалу ысулларын үзләштерү буенча үткәрелә торган күнегүләр.

*Аваз культурасы тәрбияләү* буенча эш аның сөйләм сулышы, ишетеп кабул итү, артикуляция аппаратын үстерү һ. б. шундый компонентларны үз эченә ала.

*Бәйләнешле сөйләм үстерү* сөйләмнең ике формасын - диалоглы һәм монологлы сөйләм үстерүне күздә тота. Диалоглы сөйләм үстерүдә сорау-җавап формасы, балаларның үзләренең сорау бирә, бер-берсенә мөрәҗәгать итә белүе – иң отышлы формалар. Балаларның кечкенә хикәяләрне мөстәкыйль төзи белүе монологлы сөйләм барлыкка килүдә мөһим күрсәткеч булып тора.

Балаларны *матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру* – сөйләм үсешенең әһәмиятле бурычы һәм чарасы. Матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру түбәндәге бурычларны чишкәндә тормышка ашырыла:

1. Дөньяны бербөтен итеп кабул итүне, күзаллауларны формалаштыру.

2. Әдәби сөйләмне үстерү.

3.Эстетик зәвыкны, әдәби әсәрне кабул итүне үстерү.

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишкәндә өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары кулланыла. Шундый чараларның берсе булып, бармак уеннары тора. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала, сөйләм сыйфаты, төрлелеге белән аерылып тора. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интеллект үсешенә уңай йогынты ясый. Чыннан да, физиологлар, психологлар үткәргән тикшеренүләр (Л.С. Выготский, И.П. Павлов, А.Р. Лурия, А.А. Леонтьев һ.б.) хәрәкәтләнү һәм сөйләм моторикасының үзара бәйле булуын исбатлыйлар.

Балалар белән эшләү дәверендә төрле предметлар тотып биюләр, уеннар киң кулланыла. Нәниләр уенчыкларны яшерәләр, эзлиләр, табалар. Мондый уеннар балаларда зур кызыксыну уята, тәрбияче күрсәткән хәрәкәтләрне балалар тырышып кабатлыйлар, “куян булып сикерәләр”, “кошлар булып очалар”, җим чүплиләр”, “аю кебек алпан-тилпән йөриләр”, “әтәч булып кычкыралар” һ.б. Бу уеннарда музыка әсәрләрен куллану балаларның фонематик ишетү сәләтен, ритмикасын, эмоциональ сферасын да баета, үстерә.

Нәниләр белән эшләгәндә “Җанлы картиналар” куллану зур урын алып тора. “Җанлы картиналар” - тышкы

кыяфәтләрен көтмәгәндә үзгәртәләр һәм шуның белән балаларның игътибарын җәлеп итәләр. Алар эчтәлеге буенча ике-өч төрле эшчәнлек өчен кулланыла ала. Мондый очракта эшчәнлекнең аерым эпизодларын үзгәртергә кирәк. Мәсәлән, катнашучыларның санын кыскартырга яки арттырырга, яңа элементлар кертергә мөмкин. “Җанлы картиналар”ны темалар буенча сайлау мөһим: урам, йорт һәм кыргый хайваннар, кошлар, кибет һ.б. белән таныштыру.

Балаларның игътибарын туплау, эшчәнлеккә карата кызыксыну уяту, ял иттерү (релаксация) максаты белән шигъри әсәрләргә зур игътибар бирелә. Бу әсәрләрне укыганда балалар эчтәлегенә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар: “яфраклар, кар бөртекләре кебек очалар”, “кер юалар, чайкыйлар, сыгалар”, “кояшны сәламлиләр”, “кояш нурлары ясыйлар” һ.б.

Матур әдәбият, халык иҗаты, күрсәтмәлелек, предметлар белән уен хәрәкәтләре, кошларның, җәнлекләрнең образларын имитацияләү - болар барысы да нәниләрне туган телгә өйрәтүдә, аларның сөйләмен үстерүдә зур әһәмияткә ия. Балалар белән үткәрелә торган эшчәнлек конспектлары тулы, күләмле итеп язылды. Өйрәтү-тәрбия процессында балалар белән эшчәнлекне оештырганда тәрбиячегә иҗади якын килү мөмкинлеге бирелә. Эшчәнлек конспектларын төзегәндә тәрбияче өчен күрсәтмәләр, балаларның якынча җаваплары, балаларны активлаштыру җәя эчендә күрсәтелә. Җәя эчендә күрсәтелгән индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар истә калдыру максатыннан аваз, сүз, иҗек, фраза кебек сөйләм элементын кабатлауны күрсәтә. Кабатлауның төрле вариантлары бар: тәрбияче артыннан, балалар артыннан, тәрбияче белән бергә, күмәк, индивидуаль.

Балаларны активлаштыру балаларның җавапларын конкретлаштыру, аерым сүзләрне, фразаларны, хәрәкәтләрне кабатлату максаты белән эшләнә.

# 1. МАКСАТЧАНЛЫК

## 1.1. Программаның бурычлары

*“Туган телдә сөйләшәбез” укыту –методик комплекты түбәндәге бурычларны билгели:*

- Балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү;
- Тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру;
- Бәйләнешле сөйләм үстерү;
- Тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау(тоемлау) сәләте булдыру.

“Танып белү - сөйләм үсеше юнәлешенә нигезләнеп, комплекслы - тематик планнар төзелде.

“Минем бакчам”, “Мин яратам сине, Татарстан”, “Саулык -зур байлык”, “Исеменә күрә-җисеме”, “Кунак булсаң- тыйнак бул”, “Исәнме мәктәп”, “Кояш системасы”, “Дуслык белән көчле без”, “Китап кайдан килә” һәм башка күп проектлар балалар һәм өлкәннәр тормышын чагылдыра, ана телен камил белергә, аның нечкәлекләренә төшенергә ярдәм итә, башка милләт халыклары белән дустанә мөнәсәбәттә яшәргә өйрәтә, экологик тәрбия күнекмәләре бирә, балаларда әхлакый сыйфатлар формалаштыра.

Бу укыту-методик комплектында ФГОС та күрсәткән өч белем бирү өлкәсе карала:

**-“Танып белү ” белем биру** өлкәсе балаларның туган як табигате, өлкәннәр хезмәте, ел фасыллары турындагы белемнәрен тирәнәйтүне, экологик бәйләнешләрне күрә белү мөмкинлекләрен үстерүне максат итеп куя. Шушы максатларны тормышка ашыруга ярдәм итүче зурлар төркемендә 31 эшчәнлек, мәктәпкә әзерлек төркемендә 33 эшчәнлек каралган. Балалар белән эшчәнлек сәяхәт, күзәтү, тәҗрибәләр уздыру, төрле уеннар формасында уздырыла.

**- “Аралашу” белем бирү** өлкәсе туган телнең нечкәлекләрен, тирәнлеген өйрәнү, сүзнең мәгънәсенә төшенү, логик фикерләү сәләтен үстерү, матур әдәбият әсәрләре белән кызыксыну, аваз культурасы, бәйләнешле һәм кара- каршы сөйләшә белү (диалогик сөйләм) күнекмәләрен камилләштерү, сәнгатьле сөйләмне үстерү бурычларын гамәлгә ашыра. Бу белем бирү өлкәсенә туры килгән, зурлар төркемендә 35 эшчәнлек, мәктәпкә әзерлек төркемендә 36 эшчәнлек тәкъдим ителә. Авазларны кабатлау, калын һәм нечкә авазларның дифференцациясе һәр эшчәнлеккә өлеш итеп кертелде. Бу өлкәдәге эшчәнлек әңгәмә, үстерелешле диалог(балалар сорау бирә, сорауларга җавап кайтара), сәхнәләштерү, өстәл театры карау, рәсемнәр карау, алар буенча хикәя төзү, уен-викториналар; тасвирлау, үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү, хикәяне дәвам итеп сөйләү кебек эш формаларын күздә тота.

**- “Матур әдәбият”белем бирү** өлкәсе балаларыбызны мәрхәмәтле, әдәпле, инсафлы булырга өйрәтүче, рухи сафлыкка, хезмәт сөючәнлеккә, ярдәмчеллеккә өндәүче, яшь үзенчәлекләрен искә алып сайланган шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр белән таныштыруны, әдәби телдә сөйләшергә өйрәтүне максат итеп куя. Бу белем бирү өлкәсе зурлар төркемендә 32 эшчәнлекне, мәктәпкә әзерлек төркемендә 31 эшчәнлекне үз эченә ала. Эшчәнлек матур әдәбият әсәрләрен уку,

эчтәлеген сөйләү, ятлау кебек эш формаларын кулланып оештырыла. .
Укыту-методик комплектыФДТ дә күрсәтелгән 10 белем бирү өлкәсе: (“Сәламәтлек”, “Физик культура”, Социальләштерү”, “Хезмәт”, “Куркынычсызлык”, “Танып – белү”, “Аралашу”, “Матур әдәбият уку”, “Иҗат”, “Музыка”) буенча куелган бурычларны күздә тотып эшләндеҺәм алар турыдан-туры бердәм белем бирү эшчәнлеге стуктурасында интегральләштереп бирелде.
Укыту-методик комплектында тупланган материал балалар бакчасы педагогларына балаларның сөйләмен үстерү,тирә - юнь, матур әдәбият әсәрләре белән таныштыру максатында гына түгел рәсем ясау, әвәләү, кул хезмәте, конструкцияләү, эксперимент эшләре, кисеп ябыштыру, музыка, физкультура эшчәнлекләрендә, иртән балаларны кабул итү, саф һавада булу, табигатьне күзәтү вакытында, әти-әниләр белән бердәм эшчәнлектә иҗади якын килеп кулланылыр һәм ныгытылыр дип өметләнәбез.
“Туган телдә сөйләшәбез” - балаларга телебезнең матурлыгын, байлыгын аңларга, аны тоемларга, туган телебезгә карата ярату хисләре, әти-әниләргә, өлкәннәргә карата хөрмәт тәрбияләргә, үзләрендә күркәм сыйфатлар булдырырга ярдәм итәр дип ышанасы килә.
Шушы җирдән, шушы туфрактан без.
Китә калсак үзгә бер якка,
Өянкеләр җырлап, таллар елап,
Сандугачлар моңы озата. – дип шагыйрә К.Булатованың шигырен
укыганда, балаларга туган җир, туган туфрак, туган телнең изгелеген, өянкеләрнең кайчан җырлаганын, талларның ничек итеп итеп елаганын, сандугачларның моңы ничек итеп күңелне кузгатканынаңлата алсак, без үз максатыбызга ирешкән булырбыз.

### 1.2. Программаны формалаштыруда принциплар:

***Коммуникативлылык принцибы*** – балаларны татар телен аралашу чарасы буларак куллануга әзерләүгә корылган. Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтү.
***Интеграция һәм дифференциация принцибы*** – һәр сөйләм төренең үз үзенчәлеген исәпкә алу, тәрбияче сөйләмен техник чаралар ярдәмендә (аудио-, видеоязмада) тыңлау (аудирование), тел үзәнчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү;
***Күрсәтмәлелек принцибы*** – тел өйрәтүне көндәлек тормыштагы һәр төрле эшчәнлеккә бәйле рәвештә, аларның тирә-юньне танып белүенең төп чарасы булып торган уен аша үткәрү;
***Тел өйрәтү, тәрбия һәм үстерү бурычларының бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашыру принцибы;***

***Барлык белем бирү өлкәләрен берләштерү (интегральләштерү) принцибы:*** социаль-коммуникатив, танып-белү, сөйләм үстерү, иҗади сәнгать, физик үсеш.
***Дәвамчанлык принцибы*** – балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тоту;
***Белем бирүне комплекслы-тематик принципка корып оештыру;***
***Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы*** - бала материалны үзе өчен кызык булганда, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килгәндә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Телне өйрәтү процессында әкияти сюжетлар карау, кызыклы таныш геройлар (Акбай, Мияу) белән очрашу, уен элементларын куллану – тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Телне аралашу, уен ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм алар тел материалын бик теләп үзләштерәләр.
***Белем бирү эшчәнлегенең дидактик принцибы*** - гадидән катлаулыга таба бару.
***Индивидуальләштерү принцибы*** - тел өйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүне күздә тоту. Балаларның яшь үзәнчәлекләрен исәпкә алу.

Һәр яшь төркемендә режим моментлары оештырыла. Уртанчылар төркемендә 20 минут, зурлар төркемендә 25 минут, мәктәпкә хәзерлек төркемендә 30 минут дәвам итә. Режим моментларында укыту процессы уен рәвешендә бара. Диалоглар төзү, яңа сузләр белән танышуны үз эченә ала. Ул кабатлау, үткәннәрне ныгыту, төрле уеннар, яисә мультфильм карау рәвешендә узарга мөмкин.

### 1.3. Сөйләм үстерү методикасы .

**Матур әдәбият әсәрләрен уку методикасы:**

1.Әдәби әсәрне сәнгатьле итеп уку.
2.Әдәби әсәрне максат куеп уку.
3.Әдәби әсәр эчтәлеге буенча әңгәмә уздыру.
4.Әдәби әсәрне кабатлап уку.

**Матур әдәбият әсәрләренең эчтәлеген сөйләү методикасы:**

1.Әдәби әсәрне сәнгатьле итеп уку.
2.Аңлашылмаган сүзләрне аңлату.
3.Әдәби әсәрне максат куеп уку.
4.Эчтәлеге буенча әңгәмә уздыру.
5.Әдәби әсәрне кабатлап уку.
6.Балалар тарафыннан әсәрнең эчтәлеген сөйләү.(5-6 бала)

**Шигырь ятлау методикасы.**

1.Шигырьне сәнгатьле итеп уку.
2.Шигырьне максат куеп уку.
3.Шигырь эчтәлеге буенча әңгәмә.
4.Шигырьне кабатлап уку.
5.Балалар тарафыннан шигырьне яттан сөйләү.(5-6 бала)

**Тасвирлау хикәяләре төзү планы:**

1.Бу нәрсә?(Кем?)
2.Нинди өлешләрдән тора?
3.Нәрсәдән ясалган? (нинди материал)
4.Ни өчен кирәк?

**Рәсем буенча хикәя төзеп сөйләү .**( Мурашковска И.Н. методикасы **)**

**1 адым-**“бүл.” (Рәсемдә кем нәрсә күрә, һәрбер бала аерым –аерым әйтә, тәрбияче схематик рәвештә балалар күргән һәм әйткән рәсемнәрне түгәрәккә алып тактага ясый)

**2 адым** – “әйдә.” (Балаларга эчтәлеге белән туры килгән ике рәсемне кушарга тәкъдим ителә һәм ни өчен дигән сорауга тулы җөмлә белән җавап бирүләре сорала.)

**3 адым** – “нинди тавышлар ишетәсең.” ( Уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү)

**4 адым** – “нинди исләр тоясың.” (  Уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү)

**5 адым** –“рәсемдәге әйберләрнең сыйфатларын әйтү.” (Уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү.)

**6 адым –** Хикәя төзү**. (**Биш адымны берләштерү.)

### 1.4. Балага үсеш юнәлешләре буенча белем бирү (биш белем өлкәсендә)

| Юнәлешләр | Белем бирү өлкәләре | Эшчәнлек төрләре | |
|---|---|---|---|
| Социаль-аралашу үсеше | Социальләш-терү | - сюжетлы-рольле уеннар- әңгәмәләр<br>- мультфильмнар карау | Экологик культура, табигатькә аңлы караш тәрбияләү;<br>балаларда хезмәткә карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру;үз тормышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен аңлату. |
| | Хезмәт | Хезмәт эшчәнлеге турындага балалар әдәбияты белән таныштыру | |
| | Иминлек | - уен барышында куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү | |
| Танып-белү | Танып белү | - экскурсияләр<br>- дәфтәрләрдә эш<br>- күрсәтмә әсбаплар буенча эш (санау,төсен, формасын, зурлыгын) | Туган як табигате, үсемлекләре, җәнлекләре белән танышу; |
| Сөйләм үсеше | Матур әдәбиятбелән таныштыру | - экиятләр сәхнәләштерү, шигырьләр уку<br>- мультфильмнар карау | Нәфис сүз, халык авыз иҗаты, әдәби әсәрләр, милли бәйрәмнәр аша балаларның сөйләм телен баету, уй-фикерләрен билгеле бер эзлеклелектә җиткерә белүләренә ирешү. |
| | Аралашу | - ситуатив күнегүләр<br>- сюжетлы-рольле уеннар- хикәяләр төзү, әңгәмәләр | |
| Нәфис-нәфасәти үсеш | Иҗат | - дәфтәрләрдә эш<br>- рәсем ясау, ябыштыру, әвәләү | Балаларның милли сынлы сәнгать турындагы белемнәрен баету, татар һәм Идел буе халыкларының декоратив-гамәли сәнгать үрнәкләре белән таныштыру, милли орнамент белән кием-салым, савыт-саба бизәргәөйрәтү;күренеклекомпозиторларның. |
| | Музыка | - җырлар<br>- музыкаль-дидактик уеннар<br>- җырлы-биюле уеннар (“Шома бас” дискыннан)- драма уеннары | |
| Физик үсеш | Сәламәтлек | - бармак уенары- туплар белән уеннар психогимнастика | Идел буе халыкларының хәрәкәтле уеннары аша балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту. |
| | Физкультура | - хәрәкәтле уеннар - зиһен сынаш уеннары - җырлы-биюле уеннар | |

**Социаль-коммуникатив үсеш.** Балаларның социаль характердагы беренче күзаллауларын булдыру һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү; хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру; үз тормышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң (әйләнә – тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын формалаштыру максатларын тормышка ашыра. Балаларның Татарстан Республикасы, анда яшәүче халыклар, аларның хезмәте һәм профессияләре, туган як табигате турында белемнәрен уен эшчәнлеге вакытында тирәнәйтү. Балаларда патриотизм хисләре; үзен туган шәһәре (авылы), республикасы, иленең гражданины итеп тану; шәһәр, республика, ил символикасына (флаг, герб, гимнга) хөрмәт белән карауны һәм горурлану хисе тәрбияләү. Иҗтимагый чыгышы, расасы, теле, дине, җенесе һәм яшенә карамыйча, янәшәдә яшәүчеләргә (балаларга, өлкәннәргә) уңай мөнәсәбәт, түземлек (толерантлык); башка кешеләрнең хисләре, фикерләре, теләкләренә, карашларына хөрмәт тәрбияләү, үзенең башкалар фикере белән риза булмавын дәлилли яисә үз позициясен яклый белергә өйрәтү. Башка ил, этнос халыклары белән позитив аралашуның, хезмәттәшлек итүнең мәгънәсен аңлату. Якындагы социумда үз урыны, теге яки бу төркемдәге кешеләргә нинди мөнәсәбәттә булуы (балалар бакчасындагы төркем яисә бию түгәрәге әгъзасы, спорт мәктәбе укучысы, булачак гимназист һ. б.) турында күзаллаулар формалаштыру. Гаилә тарихына (карт бабай, бабай, карт әби, әби) карата кызыксыну тәрбияләү. Гаиләң белән горурлану хисләре, гаилә әгъзаларының уңышларына сөенү, бүләкләрен игътибарсыз калдырмау күнекмәләре тәрбияләү. Идел буе халыкларының әдәби әсәрләре, нәфис һәм мультипликацион фильмнары, әйләнә-тирәдәге тормыш турындагы күзаллауларын сюжетлы-рольле һәм режиссёрлык уеннарында иҗади куллануларына булышлык итү. Балаларның сәхнәләштерү һәм кую өчен Идел буе халыкларының әкиятләрен, шигырьләрен, җырларын, биюләрен мөстәкыйль сайлап алуларын хуплау; куелачак спектакльгә кирәкле атрибутлар һәм декорацияләр әзерләргә, үзара вазифаларны билгеләргә һәм рольләр бүлешергә булышу. Театральләшкән эшчәнлектә театрның төрле төрләрен (бибабо, бармак, курчак, рәсемнәр һ. б. театрлар) куллану. Сәхнә сәнгатенә карата кызыксыну үстерү. Коллективта сүзле уеннар уйнарга омтылышларын хуплау. Идел буе халыклары уеннарын уйнау тәҗрибәсен баету.

**Танып-белү үсеше.** Балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү; Татарстан Республиканың төп символикасы, географик урыны, анда яшәүче халыкларның традицияләре, гореф–гадәтләре, йолалары белән таныштыру; туган як табигате турындагы белемнәрен киңәйтү, туган якта ешрак очрый торган үсемлек һәм хайваннарга карата кызыксынуны үстерү максатларын тормышка ашыра. Туган як тарихы, мәдәнияты, сынлы сәнгать, туган якның табигате белән таныштыру исәбенә балаларның күзаллауларын киңәйтү. Туган як табигате, климаты, кешеләренең тормышы белән таныштыруны дәвам итү. Үз шәһәренең (авылының) истәлекле урыннары, халык һөнәрләре, милли кухня, Татарстан Республикасы халыкларының тел культурасы белән таныштыру. Картада туган шәһәрен, республикасын, башкаланы, Татарстандагы эре шәһәрләрне (Әлмәт, Яр Чаллы, Түбән Кама, Бөгелмә, Яшел Үзән һ. б. ны) күрсәтә һәм атый белергә

өйрәтү. Борынгы шәһәрләр (Биләр, Болгар), аларның тарихы, культурасы, көнкүреше белән таныштыру. Авыл һәм шәһәр кешеләренең көнкүрешен чагыштырырга өйрәтү. Татар һәм рус халкының яши торган өе, йорт кирәк-яраклары, өс киемнәре үзенчәлекләренә игътибар итү. Туган шәһәрендә бара торган позитив үзгәрешләрне (балалар бакчалары, спорт комплекслары, театрлар һ. б. төзелү) күрә белергә өйрәтү. Казанның эре промышленность һәм сәүдә үзәге булуы, татар халкының элек-электән игенчелек, терлекчелек, күн эшкәртү, сәүдә белән шөгыльләнүе турында балаларга сөйләү. Туган шәһәренең, башка шәһәрләрнең символикасын өйрәнүне дәвам итү, үз халкының бер өлеше булуын аңлый белергә ярдәм итү. Милли һәм дөнья культураларының үткәненә һәм бүгенге сенә балаларны якынайту. Музыка һәм театр сәнгатенең күренекле шәхесләре, аларның тормыш һәм иҗат юллары белән таныштыру (композиторлар: С. Садыйкова, С. Сәйдәшев, Ф. Яруллин һ. б., җырчылар: Ф. Шаляпин, И. Шакиров, Р. Ибраһимов һ. б., театр режиссёрлары: М. Сәлимҗанов, К. Тинчурин һ. б., В. Качалов, Г. Камал исемендәге театр актёрлары һ. б.). Аларның тормышларына һәм эшчәнлекләренә кызыксыну уяту. Күренекле фән эшлеклеләренең тормышы һәм эшчәнлекләре белән таныштыру (Н. И. Лобачевский, К. Ф. Фукс, И. М. Симонов, Н. Н. Зинин, А. М. Бутлеров, А. Е. Арбузов һ. б.). Балаларның танып белүгә карата кызыксынуларын канәгатьләндерү, Казан (Идел буе) федераль университеты укытучылары һәм аны тәмамлаучылар турында мәгълүмат бирү. Милләтебез каһарманнарының Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары турында сөйләү (М. Җәлил, Г. Гафиятуллин, М. П. Девятаев, П. М. Гаврилов, Н. Г. Столяров һ. б.). Әти-әниләрне балаларга әби һәм бабаларының сугышта алган бүләкләре турында сөйләргә җәлеп итү. Ватанны саклаучыларга карата хөрмәт хисләре тәрбияләү (һәйкәлләр, обелискларга чәчәкләр кую һ. б.). Табигатьне саклау буенча балаларның белемнәрен тирәнәйтү. Туган якның тере һәм тере булмаган табигатенә сакчыл караш тәрбияләү, табигатькә катнашуыңнан соң туган уңай һәм тискәре нәтиҗәләрне алдан күрә белергә өйрәтү, табигатьнең ресурсларына сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү, аны рациональ файдалану күнекмәләре формалаштыру. Үсемлек һәм җиләкләрне җыю кагыйдәләре белән таныштыру. Дәүләт тыюлыклары, анда яшәүче тереклекияләре, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән үсемлек (флора) һәм хайваннар (фауна) төрләре белән таныштыруны дәвам итү. Хайваннар һәм үсемлекләр дөньясында сирәк очрый торган төрләргә сакчыл караш кирәклеген балаларның аңнарына җиткерү. Татарстанның елга, күлләрендә яшәүче тереклек ияләре белән таныштыру. Кеше тормышында чишмә, елгаларның тоткан урыны, әһәмияте турында сөйләү. Республика сулыкларын чиста тотарга теләк уяту. Туган як табигатенең матурлыгына, андагы форма, ис, төс муллыгына игътибар итү. Табигатьтәге үзгәрешләрне күрә белергә өйрәтү.

**Сөйләм үсеше.** Әйләнә–тирәдәге кешеләрнең үзара мөгамәләсенең конструктив ысул һзм чараларын үзләштерү; балада китап укуда кызыксыну һәм ихтыяҗ формалаштыру максатларын тормышка ашыра. Балаларны матур әдәбият әсәрләре, халык әкиятләре, фольклоры белән таныштыру. Татар теленә карата тотрыклы кызыксыну үстерү. Мәгълүмати аралашу технологияләре, аудио- һәм видеоязмалар, уку-укыту методик комплектлары ярдәмендә предметны, аның билгесен,

хәрәкәтен белдерүче сүзләрне актив кулланышка кертү, гади аралашу өчен кирәк булган сөйләм берәмлекләре байлыгы булдыру. Балаларның сүз байлыгын арттыру. Төзелеше ягыннан катлаулы булмаган хикәя һәм сорау җөмләләр төзү күнекмәләрен ныгыту. Үзе турында, бер кеше гамәлләрен сурәтләгән ситуатив картиналар сериясе буенча, сюжетлы рәсемнәр, үз күзәтүләреннән чыгып, зур булмаган (3–5 җөмләле) хикәяләр төзи белергә өйрәтү. Балаларның төрле эшчәнлек вакытында татар халык фольклор әсәрләрен, еш кулланыла торган сүзләр һәм әйтемнәрне файдалануга омтылышларын хуплау. Татар телендә сөйләүче әңгәмәдәшенең сөйләмен тыңлый белүне формалаштыру, нәрсә турында сөйләгәнен аңларга тырышу, телне аз белүенә карамастан, аның белән әңгәмәгә кереп, аралашырга омтылышын хуплау. Балаларны татар телен киләчәктә (башлангыч мәктәптә) тагын да аңлабрак, төшенеп өйрәнергә әзерләү.

**Нәфис-нәфасәти үсеш.** Балаларда әйләнә–тирәдәге матурлыкка кызыксыну уятуны һәм үзләрен күрсәтү ихтыяҗларын канәгатьләндерүне; балаларның музыкальлекләрен, музыканы, матур әдәбият, фольклор әсәрләрен хис-тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү максатларын тормышка ашыра. Балаларны татар халкының сәнгате (музыка, бию, рәсем сәнгате, матур әдәбият әсәрләре), анда яшәүче атаклы кешеләр белән таныштырып, аларда әхлакый-патриотик хисләр тәрбияләү. Милләтебезнең дини йолалары, халык авыз иҗаты, сынлы сәнгате һәм архитектурасы, музыка сәнгате белән таныштыру балаларда Туган илне ярату хисе тәрбияләргә булыша. Милли орнамент элементлары белән таныштыруны дәвам итү. Балалар белән «яшәү агачы» образын карау. Балаларның игътибарын композициянең үзенчәлегенә (симметриясез), шул ук вакытта төрле төсләр файдаланылган чәчәк бәйләменә юнәлдерү. Төрле материаллар кулланырга, реаль һәм әкияти образларны (Идел буе халыклары әкиятләрендәге геройларны да кертеп) сурәтләүнең төрле ысулларын берләштерергә мөмкинлекләр бирү. Республика тормышында булган истәлекле вакыйгаларны рәсемнәрдә чагылдыра белүләрен хуплау. Балаларның эшләрен бергәләп карау, нәрсә ясаганнары турында сөйли белергә өйрәтү. Балаларга эшләренең тематикасын киңәйтүгә булышлык итү. Актүбә һәм Шәмәрдән уенчыкларын натурадан карап әвәли һәм аларның характерлы үзенчәлекләрен бирә белергә өйрәтү. Ике-өч фигурадан торган скульптура төркемнәрен катлаулы булмаган сюжетларга («Сабантуйда», «Чәй эчкәндә», «Ат чабышлары» һ. б.га) берләштерү. Идел буе халыкларының әдәби әсәрләре геройларын күзаллау юлы белән әвәли белү күнекмәләрен формалаштыру. Туган шәһәре (авылы) тормышындагы вакыйгаларны чагылдыручы сюжетларны мөстәкыйль сайлый белүләрен активлаштыру. Башка белем бирү өлкәләренең эчтәлеге белән ярак-лаштырып, балалар эшләренең тематикасын киңәйтү. Балаларны Г. Тукай әсәрләре һәм аның иҗатын чагылдыручы сәнгать төрләре (Ф. Яруллинның «Шүрәле», Ә. Бәшировның «Су анасы» балетлары, Н. Җиһановның «Кырлай» симфониясе, Б. Урманче, И. Казаков, Б. Әлменов, Ф. Әминов һ. б. ның сынлы һәм рәсем сәнгатьләре әсәрләре) белән таныштыруны дәвам итү. Сәнгатькә карата уңай караш формалаштыру. «Казан» милли-мәдәни үзәгенең милли-мәдәният музеенда булу, анда борынгыдан сакланып калган өй кирәк-яраклары: көмеш поднослар, савыт-саба, бизәк төшерелгән бакыр кувшиннар, комганнар, йорт хайваннары фигуралары формасындагы

бронза йозаклар; җәмәгать биналарының интерьерларын һәм экстерьерларын бизәүче декоратив композицияләр белән таныштыру. Борынгы бизәнү әйберләрен: йөзекләр, алкалар, беләзекләр, чулпылар, яка чылбырлары, хәситәләр һ. б.ны карау. Хәзерге заман рәссам-ювелирларның (И. Фазылҗанов, С. В. Ковалевская, В. О. Ковалевский һ. б.ның) иҗатлары белән таныштыру. Балаларның игътибарын бизәнү әйберләренең милли үзенчәлекләренә юнәлдерү. Татар халкының үзенчәлекле сәнгати һөнәре булган укабелән чигү турында сөйләү. Чигелгән түбәтәйләр, хатынкызның бәрхет аяк киеме, күкрәкчәләр, калфаклар һ. б.ны карау. Бигрәк тә популяр булган композицияләргә – «алтын каурый», чәчәк бәйләме, кошлар, бодай башагы, йолдызлар һәм ярымай мотивларына һ. б.га игътибар итү. Туган шәһәр (авыл) архитектурасы – мәчет һәм храм архитектуралары (Кол Шәриф мәчете, Раифадагы Богородицкий ир-атлар монастыре) белән таныштыру эшен дәвам итү. Балаларны татар халкының музыка культурасына якынайту. Татар композиторларының музыкаль әсәрләрен тыңлау. Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең Дәүләт гимннары белән таныштыру. Горурлык хисләре тәрбияләү.

**Физик үсеш.** Балаларның сәламәтлеген саклау, аларда сәламәтлек культурасы нигезләрен формалаштыру; физик культура эшчәнлегенә кызыксыну һәм аңлы караш, гармонияле физик үсеш формалаштыру максатларын тормышка ашыра. Татар халык хәрәкәтле уеннарын, физминуткалар кулланып балаларның хәрәкәт активлыгын үстерү, татар халык бәйрәмнәре, халык уеннары аша балаларның физик үсешен камилләштерү. Чәй янына бирелә торган милли камыр ризыклары: гөбәдия (дөге, йөзем һәм йомырка белән), кабартма, бавырсак, талкыш-каләвә, чәкчәк, кош теле белән таныштыру. Балаларга республикадан читтә дә танылган дәвалану-ял итү урыннары һәм санаторийлар («Васильево», «Сосновый бор» («Нарат урманы»), «Крутушка», «Бакирово», «Санта» һ. б.) белән танышу мөмкинлеге бирү. Хәрәкәтле халык уеннарын үзгәртеп төрләндерү күнекмәләре бирү. Милли уен-ярышларда («Таяк тартыш», «Аркан тартыш», «Капчык белән сугыш» һ. б.да) катнашасы килү теләге уяту. Кеше тормышында спортның әһәмияте турында күзаллау формалаштыру. Милли спорт төре – көрәш белән таныштыру. Спорт өлкәсендәге билгеле уңыш-казанышлар белән таныштыру. Идел буе халыкларының төрле эчтәлекле уеннарын мөстәкыйль эшчәнлек вакытларында файдалана белү күнекмәләрен ныгыту. Хәрәкәтле уеннарда балаларда көч, җитезлек, кыюлык, тәвәккәллек, түземлек кебек сыйфатлар тәрбияләү. Уен нәтиҗәсен гадел бәяли белүләрен хуплау. Халык уеннары белән кызыксынуларын үстерү.

## 1.5. Эш төрләре һәм формалары

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур.

Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:

1.Эшчәнлек эшкәртмәләре, диагностик материаллар.

2.Тавышлы күрсәтмәлелек (һәр проект өчен аудиоязмалар, анимацион сюжетлар, мультфильмнар).

3.Картиналы һәм картиналы-дидактик күрсәтмәлелек (таратма һәм күрсәтмә рәсемнәр, җырлы-биюле уеннар, театр эшчәнлеге өчен материаллар.

4.Символик, график күрсәтмәлелек (пиктограммалар).

5.Күләмле күрсәтмәлелек (макетлар, муляжлар, уенчыклар)

6.Интерактив уеннар.

7.Эш дәфтәрләре.

**Эш төрләре һәм формалары:**

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур. Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:

1.Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу.

2.Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.

3.Сюжетлы-рольле уеннар;

4.Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).

5.Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү (әти-әниләргә, башка төркем балаларына).

6.Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, “Командир” уены, әйлән-бәйлән уен, зарядка уеннары.

7.Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.

8.Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү.

9.Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу).

10.Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү.

11.Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау.

12.Интерактив уеннар.

**Аудиоязмалар**

Аудиоязмалар яңа сүз өйрәтү, сөйләм үрнәкләре үзләштерү, уеннар, кыска җырлар өйрәтү, өстәл театры күрсәтү вакытларында куллану өчен кулай. Аларны һәр эшчәнлектә куллану мөһим түгел.

**Яңа сүзләр өйрәтү технологиясе**

Балаларны татар телендә сөйләшергә һәм аралашырга өйрәтү билгеле бер күләмдәге сүз байлыгы булдырудан башлана. Яңа сүзләр үзләштерү процессында махсус сайлап алынган күнегүләр төп чара булып тора. Юнәлеше һәм характеры ягыннан лексик күнегүләрне икегә бүлеп карыйлар: әзерлек күнегүләре һәм сөйләм күнегүләре. *Әзерлек күнегүләре* балаларны яңа сүзләрне файдаланып сөйләргә әзерли. Бу күнегүләр лексик берәмлекләрне хәтердә калдырырга ярдәм итәләр. *Сөйләм күнегүләре* лексик күнегүләрнең бер төре буларак, үзләштерелгән лексик берәмлекләр җирлегендә ситуацияләргә бәйле сөйләм эшчәнлеген барлыкка китерәләр. Яңа сүз өйрәтү төп методик алымнарның берсе булып тора:

-яңа сүз тәрбияче тарафыннан ачык, төгәл итеп күрсәтмә рәсем ярдәмендә әйтелә;-аудиоязмадан тыңлатыла, кабатлатыла;

-ишеткән сүзне бала рәсемннән табып күрсәтә һәм әйтә;

-сүзләр тизрәк истә калсын өчен сүз кат-кат әйттерелә, аңлашылмаган очракта, аның русча тәрҗемәсе бирелә;

-төрле эш формаларында (пышылдап, күмәкләп, төркемнәргә бүленеп, хәрәкәтләнеп әйтеп) өйрәтелә;

-уеннар кулланып (“Ватык телефон”, “Кайтаваз”...) ныгытыла;

-яңа сүз, таныш булган сүзләр белән грамматик конструкцияләрдә ныгытыла, мәсәлән: зур туп, чиста туп;

-аралашуда кулланыла (бала өйрәнгән яңа сүзләрне, конструкцияләрне бары аралашуда аңлап куллана);

-бала теге яки бу сүзне аның төгәл мәгънәсен аңлап үзләштереп калсын өчен телдән инкарь итү яисә раслау күнегүләре үткәрергә мөмкин; өйрәнелгән сүзләрне хәтердә калдыру максатыннан төрле уеннар оештырырга була: “Исемен әйтсәң бирәм”, “Мин күрсәтәм, син әйт”, “Сорап ал”, “Серле кәрзин” һ.б.

Баланың сөйләмен оештыру өчен исемнең алмашлык (мин, син, бу), сан (1 дән 10 га), сыйфат (тәм, күләм, төс, эчке сыйфатлар) һәм фигыль белән бәйләү грамматик конструкцияләре кулланыла. Фигыль белән таныштыру боерык фигыльләрдән башлана (бар, сикер, аша һ.б.). Уртанчылар төркемендә балаларга боерык фигыльләрне аңлап үтәүләрен таләп ителә. Зурлар төркемендә балалар кайбер боерыкларны үзләре бирә (сикер, аша, уйна) һәм аңлап үтиләр. Мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә балалар үзлектән Нишли? Син нишлисең? сорауларын бирәләр һәм аңлап җавап кайтаралар.

**Диалогик сөйләм**

Программаның төп асылы булып аралашуга чыгу тора. Аралашуга чыгу өчен диалогик сөйләмнең әһәмияте бик зур. Диалогик сөйләмгә өйрәткәндә гадидән катлаулыга дигән дидактик принципка таянып эшләү кулай. Диалогик сөйләмдә иң отышлы алым – сорау-җавап рәвешендә (сорау-информация алу берәмлеге) һәм теләк белдерә торган: теләк, үтенү, тәкъдим итү, ризасызлык төсмере булырга мөмкин. Еш кына сораудан соң, әңгәмәдәшнең җавап репликасы килә, раслау яисә инкарь рәвешендә булырга мөмкин.Реплика-җавап сорау рәвешендә дә булырга мөмкин: *Нинди эти?* Бу вакытта әңгәмәдәшнең җавабы тулы да, ким дә булырга мөмкин: *Матур эти;* яисә: *Матур.*

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга ситуатив - тематик принцип нигезендә, диалогик сөйләмне үстерү буенча түбәндәге типтагы күнегүләр тәкъдим итәргә мөмкин:

- уен ситуацияләрендә катнашу;
- тәкъдим ителгән үрнәк буенча кечкенә диалоглар төзү;
- тематик диалоглар төзү;
- сәхнәләштерүдә катнашу;
- рольләргә бүлеп сөйләү.

Диалоглар белән эшләү коммуникатив юнәлештә алып барылырга тиеш. Тәрбияче аларның балалар сөйләменә кирәкле формаларын эшләргә һәм төрле шартларда куллану мөмкинлеген исәпкә алырга тиеш. Тәрбияче, сөйләмгә эмоциональ бизәлеш өстәү өчен, төрле формаларны кулланырга; эш эчтәлегенә туры килә торган интонация, ишарәләр, мимикалардан файдаланырга һ.б. өйрәтергә тиеш. Шул ук вакытта, диалогны сорау бирү һәм аңа җавап алу дип кенә уйларга ярамый. Балаларны диалогик сөйләмгә хас булган башка (сорау һәм җаваплардан тыш) ситуацияләр, репликалар, көндәлек аралашу формаларына да өйрәтергә кирәк.

### 1.6. Төрле эшчәнлекләрдә белем бирү формалары

<table>
<tr><th>Хәрәкәт</th><th>Уен</th><th>Хезмәт</th><th>Танып-белү</th><th>Аралашу</th></tr>
<tr><td>-уен<br>-хәрәкәт элементларын кулланып әңгәмә үткрү<br>-физминуткалар</td><td>-күзәтү<br>-уку<br>-уен<br>-әңгәмә<br>-күмәк уен (тәрбияче; балалар белән)<br>-сюжетлы-рольле уен<br>-кагыйдәле уен<br>-экскурсия<br>-бәйрәм</td><td>-күмәк эшчәнлек<br>-әңгәмә<br>-карау<br>-уен<br>-дежур тору</td><td>-күзәтү<br>-сюжетлы-рольле уен<br>-хикәя<br>-үстерүле уен<br>-әңгәмә<br>-ситуатив сөйләшү<br>-уку</td><td rowspan="3">-уку<br>-хикәя<br>-әңгәмә<br>-өстәл театры<br>-балалар белән аралашу<br>-шигыр ятлау<br>-уен (дидактик, театральләштерелгән, режиссер)<br>-табышмакларга җавап табу<br>-текстлы хәрәкәтле уен<br>-тәрбияче белән аралашу</td></tr>
<tr><td>Матур әдәбият, фольклорны кабул итү</td><td>Рәсем</td><td>Музыка</td><td>Төзү</td></tr>
<tr><td>-уку, әңгәмә, хикәя, уен,викторина<br>-инсценирование</td><td>-<br>карау,уен,бизәү,күргәзмәләр<br>-ясау</td><td>-музыка тыңлау<br>-җырлы-биюле уен<br>-җырлау</td><td>-уен<br>-күзәтү<br>-карау</td></tr>
</table>

## 2. ЭЧТӘЛЕКЛЕ

### 2.1. Комплекслы тематик план. Беренче кечкенәләр төркеме

| № | Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|---|
| 1. | **Танышу** | Танышу | 6 |
| 2. | **Безнең балалар бакчасы** | Аю белән куян кунакка килгән<br>Куянга өй төзибез<br>Курчагым<br>“Үчтеки, үчтеки” такмагын уку<br>Курчакның туган көне<br>Карусельгә сәяхәт<br>Минем матур тубым<br>Әминә Бикчәнтәеваның “Туп-туп, тубыбыз” шигырен уку<br>Уенчыклар кибетендә | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 3. | **Көз** | Көз җитте<br>Көзге яфраклар<br>”Безнең Алсу “ сериясеннән рәсем карау<br>Яшелчәләр<br>Куян кунакка килгән<br>“Шалкан” әкияте<br>Җиләк-җимешләр<br>Әбидә кунакта<br>Яшелчә бакчасында | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 4. | **Мин - дөньяның бер кешесе** | Минем исемем бар<br>Бу — мин<br>Мин –дөньяның бер кешесе | 1<br>1<br>1 |
| 5. | **Гаилә** | Минем гаиләм<br>Безнең гаилә<br>Әйдәгез дуслашыйк<br>Бу өйдә кем яши?<br>Без чәбәкәй итәбез | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Уйнарга яратабыз<br>“Гаилә” рәсемен карау<br>Шәйхи Маннурның “Яратам” шигырен уку<br>Әйдәгез уйныйбыз | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 6. | **Кыш** | Ап-ак кар ява<br>Алсу урамга җыена<br>Кар бабай ясау<br>Кыш рәсемен карау<br>Кар ява<br>А.Алиш “Куян кызы” | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 7. | **Яңа ел бәйрәме** | Яшел чыршы<br>Әминә Бикчәнтәеваның «Беренче адым» шигырен уку<br>Чыршы бизибез<br>Куян чыршы янында<br>Купшы чыршы<br>Без музыка залында | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 8. | **Минем әйләнә - тирәм** | Яраткан уен бүлмәбез<br>Алсу бүлмәсе<br>Безнең урам<br>Безнең апа<br>Алсу авырган<br>Алсуда  кунакта<br>Безнең йортта кемнәр яши?<br>Йорт кошлары<br>Хайваннарны чакыру<br>Маэмаем<br>М.Җәлилнең “Әтәч” шигырен уку<br>Гав исемле мәче баласы<br>Габдулла Тукай  “Гали белән Кәҗә”<br>“Чуар тавык” әкияте | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Әкияттә кунакта | 1 |
| 9. | **Әтиләр-бабайлар** | Зур гаилә<br>Безнең әтиләр һәм абыйлар<br>Бабайга кунакка барабыз<br>Машина<br>Самолет<br>Булатның машинасына гараж ясау | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 10. | **Әниләр-әбиләр** | Кибеткә бару<br>Әбидә кунакта<br>Безнең әниләр<br>Алсуны табибка алып барабыз<br>Табибка барабыз<br>Курчакны йоклату | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 11. | **Халык иҗаты** | Хайваннарны чакыру<br>”Йомры икмәк” рус халык әкиятен уку<br>“Шалкан” әкиятен уку<br>“Камыр малай” әкиятен сөйләү<br>“Теремкәй” рус халык әкиятен уку<br>Өч аю | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 12. | **Яз** | Урамда яз<br>Яз җитә<br>Яз<br>Җәнлекләр урманда яшиләр<br>Язгы урманда<br>Агачлар<br>Агачлар<br>Каргалар<br>Кошлар<br>Яз килде<br>Кояш, чык, чык! | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Урманда зур концерт” | 1 |
| 13. | **Җәй** | Бүлмә гөлләре<br>Бүлмә гөлләре<br>Мультфильмда кунакта<br>Куаклар<br>Чәчәкләр<br>Балалар бакчасы ишек алдында<br>Экология сукмагы буенча сәяхәт<br>Су белән уен<br>Мультфильмда кунакта<br>Рәхмәт, җәй!<br>Әнәс Кариның “Чебиләр” шигырен уку<br>Уеннар | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | | | **105 сәгать** |

## 2.2.“Туган телдә сөйләшәбез”.Комплекслы тематик план.Икенче кечкенәләр төркеме (3-4 яшь)

| № | Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|---|
| **1.** | **Исәнме, балалар бакчасы** | Танышу | 1 |
| | | Өйдә кем яши? | 1 |
| | | Мин малай, мин кыз | 1 |
| | | Мияу белән танышу | 1 |
| | | Әйдәгез танышыйк | 1 |
| | | Әйдә дуслашыйк | 1 |
| **2.** | **Уенчыклар** | Минем яраткан уенчыкларым | 1 |
| | | Минем яраткан уенчыкларым | 1 |
| | | Карусельгә сәяхәт | 1 |
| | | Без уйнарга яратабыз | 1 |
| | | Йомшак уенчык карау | 1 |
| | | Туп | 1 |
| | | Туган көн | 1 |
| | | Мияу кунакка килгән | 1 |
| | | Уенчыклар кибете | 1 |
| **3.** | **Көз** | Алтын көз | 1 |
| | | Көз килде | 1 |
| | | Аваз культурасы, Ө авазы | 1 |
| | | Куян үстергән кишер һәм помидор | 1 |
| | | Яшелчә бакчасында | 1 |
| | | “Шалкан” әкияте | 1 |
| | | Җиләк-җимеш бакчасында | 1 |
| | | Бакчада алмалар өлгерде | 1 |
| | | Уйный-уйный саныйбыз | 1 |
| **4.** | **Гаилә** | Өйдә кем яши? | 1 |
| | | Безнең гаилә | 1 |
| | | Качышлы уйныйбыз | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Тату гаилә<br>Минем дуслар<br>Әйдәгез дуслашыйк<br>Минем туганнарым<br>Безнең гаилә<br>Әби күчтәнәче<br>Дустыңны сыйла<br>Сөт,чәй<br>Кунакка барабыз | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| **5.** | **Кыш** | Кар ява<br>Алсуны урамга киендерәбез<br>А.Алиш “Куян кызы”<br>“Чанада шуабыз” рәсемен карау<br>Кышкы уеннар<br>“Куяннар”уенын өйрәнү | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| **6.** | **Яңа ел бәйрәме** | Тиздән чыршы бәйрәме<br>Б.Рәхмәтнең “Кыш бабай” шигырен ятлау<br>Уйныйбыз да, җырлыйбыз да<br>Без бәйрәмгә әзерләнәбез<br>Бәйрәм концерты<br>Яңа ел бәйрәме | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| **7.** | **Минем йортым, минем шәһәрем** | Минем шәһәрем<br>Мин “КамАЗ” оныгы<br>“Әлли-бәлли итәргә...”бишек җыры<br>Безнең урам<br>Алсуның яңа өе<br>Алсуда кунакта | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| **8.** | **Безнең авылда** | Безнең авылда<br>Зурлар һәм кечкенәләр<br>“Кем нәрсә ярата?”татар халык әкиятен сөйләү | 1<br>1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Песи һәм песи балалары”рәсемен карау<br>Җ.Тәрҗемановның”Үзен бик чиста йөртә”шигырен уку<br>“Кем МИЯУ дип әйтте?”<br>Йорт кошлары<br>Р.Батулланың “Елак әтәч”әсәрен уку<br>Без уйныйбыз | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| **9.** | **Ватанны саклаучылар көне** | Зур гаилә<br>Безнең әтиләр һәм абыйлар<br>Бабайга кунакка барабыз<br>Ватанны саклаучылар көне<br>Очучылар<br>З.Туфайлованың “Шофёр булам”шигырен уку | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| **10.** | **8нче март** | Минем әнием<br>Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа!<br>Без әнигә булышабыз<br>Әбигә кунакка барабыз<br>Мин әнинең ярдәмчесе<br>Азат кунак чакыра | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| **11.** | **Кыргый хайваннар** | Урманда<br>Аю белән куян<br>“Өч аю”әкияте | 1<br>1<br>1 |
| **12.** | **Әкияттә кунакта** | “Теремкәй” рус халык әкиятен сөйләү<br>Кыргый хайваннар<br>“Төлке, куян һәм әтәч”әкиятен сәхнәләштерү | 1<br>1<br>1 |
| **13.** | **Яз** | Урамда яз<br>Яз җитте<br>Яз җыры<br>“Кояш чык,чык,...”<br>Язгы күренешләр<br>Ак аю кунакка килгән | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Кошлар<br>Х.Вахитның “Уңган сыерчык”шигырен уку<br>Без уйныйбыз | 1<br>1 |
| 14. | **Бәйрәмнәр** | Бәйрәмгә барабыз<br>“Балалар бакчасында бәйрәм” дигән рәсем карау<br>“Урманда зур концерт” - анимацион сюжет карау | 1<br>1<br>1 |
| 15. | **Җәй** | Автобуста сәяхәт<br>Җ.Тәрҗемановның “Кикрикүк” шигырен уку<br>Мультфильмда кунакта<br>М.Мазуновның “Кәҗә”шигырен уку<br>“Кәҗә һәм кәҗә бәтиләре” рәсемен карау<br>Чәчәкләр-тормыш яме<br>Матур җәй, кил безгә<br>Мин җәйне яратам<br>“Карга” эндәшен уку<br>Саф һавада<br>Экология сукмагы буенча сәяхәт<br>Без уйныйбыз | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | | | **105 сәг.** |

## 2.3. Беренче кече яшьтәгеләр төркемендә сөйләм телен үзләштерү дәрәҗәләренә диагностика

**Диагностик биремнәр (5-14 ноябрь)**

**1. Баланың сүзлек запасы**

1). Дидактик уен “Бу нәрсә?”

Материал: уенчыклар, җиләк-җимеш, яшелчәләр сурәтләнгән предметлы картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага уенчыклар (машина, курчак, туп) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы уенчыкларны атарга куша: - Бу нәрсә? Аннары предметларның өлешләрен күрсәтергә тәкъдим итә. Мәсәлән: машинаның кабинасын күрсәт. – Кузовын күрсәт. - Тәгәрмәчләрен күрсәт.

Тәрбияче балага җиләк-җимешләр (алма, груша, слива) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы җиләк-җимешләрне атарга куша: - Бу нәрсә? Балаларга җиләк-җимешләрнең төсләрен (кызыл, яшел, сары) атарга тәкъдим итәләр.

Тәрбияче балага яшелчәләр (кишер, кыяр, помидор) сүрәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы яшелчәләрне: - Бу нәрсә? Балаларга яшелчәләрнең төсләрен (кызыл, яшел, кызыл) атарга тәкъдим итәләр.

2). Дидактик күнегү “Син кем?”

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче баланы үзе янына чакыра, аңа сораулар бирә: - Синең исемең ничек? - Ә минем исемем ничек? - Мин кыз, ә син кем? – Башыңны күрсәт әле. – Кая синең борының (күзләрең, колакларың, кулларың, аякларың)?

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – предметларның исемен атаганда, төсләрен билгеләгәндә хаталар җибәрә. Тәрбияченең сорауларына җавап бирә алмый.

**2 балл** – предметларның исемен дөрес атый, төсләрен билгеләгәндә хаталар җибәрә. Тәрбияченең сорауларына өстәмә сораулар ярдәмендә генә җавап бирә.

**3 балл** – предметларның исемен дөрес атый, төсләрне дөрес билгели. Тәрбияченең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

**2. Сөйләмнең грамматик ягы**

1). Дидактик уен “Кем нәрсә эшли?”

Материал: табибә, шофёр, сатучы сурәтләнгән сюжетлы картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага табибә төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Табибә). Ул нәрсә эшли?

(Тыңлый). Ул кемне дәвалый? (Малайны дәвалый).

Тәрбияче балага шофёр төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Шофёр). Шофёр кайда утыра? (Кабинада утыра). Ул нәрсә эшли? (Машина йөртә).

Тәрбияче балага сатучы төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Сатучы). Сатучы кайда эшли? (Кибеттә (магазинда). Ул нәрсә эшли? (Ул әйбер сата).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала биремнәрне үти алмый. Тәрбияченең сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә бала хаталар ясый.

**2 балл** – бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбияченең сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә.

**3 балл** – бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбияченең сорауларына җавап биргәндә исем белән фигыльне, алмашлык белән фигыльне яраклаштыра ала. Тәрбияченең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

**3. Сөйләмнең аваз культурасы**

1). Дидактик уен “Бу нәрсә? Ул ничек кычкыра?”

Материал: песи, эт, әтәч, сыер, күгәрчен, чыпчык сурәтләнгән картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага песи (эт, әтәч, сыер, күгәрчен, чыпчык) төшерелгән картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: - Бу нәрсә? (Эт). Эт ничек өрә? (Һау-һау). - Бу нәрсә? (Песи). Песи ничек кычкыра? (Мияу-мияу). - Бу нәрсә? (Әтәч). Әтәч ничек кычкыра? (Кикрикүк). - Бу нәрсә? (Сыер). Сыер ничек мөгри? (Му-у). - Бу нәрсә? (Күгәрчен). Күгәрчен ничек гөрли? (Гөр-гөр). - Бу нәрсә? (Чыпчык). Чыпчык ничек чыркылдый? (Чырык-чырык).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала 1-2 биремне генә үти ала.

**2 балл** – бала биремнәрне тәрбияче ярдәме белән башкара, аның артыннан кабатлый.

**3 балл** – бала биремнәрне теләп башкара. Аваз иялтемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә.

**4. Бәйләнешле сөйләм**

1). Сюжетлы картина буенча әңгәмә

Материал: уйнаучы балалар сурәтләнгән сюжетлы картинка.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

- Карагыз әле, Йомшаккай бик матур бер картинка ясаган. – Бу картинкада кем ясалган? – Балалар нәрсә эшлиләр? - Картинка сиңа ошыймы?

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала сорауларга ишарәләр яки бер сүз белән генә җавап бирә.

**2 балл** – бала җавап биргәндә 2-3 сүздән торган гади җөмләләргә өстенлек бирә.

**3 балл** – бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди? кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үзенең инициативасы яки тәрбиячәнең үтенече буенча картинада сурәтләнгәнне сөйли ала.

**Югары дәрәҗә** - 10-12 балл.
**Уртача дәрәҗә** - 6-9 балл.
**Түбән дәрәҗә** - 3-5 балл.

## Диагностик биремнәр

**1. Баланың сүзлек запасы**

1). Дидактик уен "Бу нәрсә?"

Материал: савыт-саба, йорт җиһазлары, йорт хайваннары, кыргый хайваннар, киемнәр сурәтләнгән предметлы картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага савыт саба (тәлинкә, чынаяк, чәй тәлинкәсе, табак) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Савыт-саба).

Тәрбияче балага йорт җиһазлары (караватъ, өстәл, урындык, шкаф) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт җиһазлары).

Тәрбияче балага йорт хайваннары (эт, песи, сыер, кәҗә) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт хайваннары).

Тәрбияче балага кыргый хайваннар (куян, төлке, аю) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы хайваннарны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Кыргый хайваннар).

Тәрбияче балага киемнәр (күлмәк, куртка, башлык) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Киемнәр).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – предметларның исемен атаганда авырлыклар кичерә, гомумиләштерүче сүзләрне куллана алмый.

**2 балл** – предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне белдергәндә хаталар җибәрә.

**3 балл** – предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне дөрес билгели.

**2. Сөйләмнең грамматик ягы**

1). Дидактик уен “Кем нәрсә эшли?”

Материал: китап укучы әни, өрә торган эт, уйный торган малай, рәсем ясаучы кыз сурәтләнгән сюжетлы картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага китап укучы әни төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Әни). Әни нәрсә эшли? (Укый). Әни нәрсә укый? (Әни китап укый).

Тәрбияче балага өрә торган эт төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу нәрсә? (Эт). Эт нәрсә эшли? (Эт өрә). Ул ничек өрә? (Эт һау-һау дип өрә).

Тәрбияче балага уйный торган малай төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Малай). Малайның исеме ничек? (Бала малайга исем биреп карый). Малай нәрсә эшли? (Малай уйный). Ул нәрсә белән уйный? (Ул машина белән уйный).

Тәрбияче балага рәсем ясаучы кыз төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Кыз). Кызның исеме ничек? (Бала кызга исем биреп карый). Кыз нәрсә эшли? (Кыз рәсем ясый). Ул нәрсә белән рәсем ясый? (Ул карандаш белән рәсем ясый). Кыз нәрсә рәсеме ясый? (Кыз кояш рәсеме ясый).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала биремнәрне үти алмый. Тәрбияченең сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә бала хаталар ясый.

**2 балл** – бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбияченең сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә.

**3 балл** – бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбияченең сорауларына җавап биргәндә җөмләләрне грамматик яктан дөрес төзи. Җөмләләрнең иясе һәм хәбәре бар. Тәрбияченең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

**3. Сөйләмнең аваз культурасы**

1). Дидактик уен “Бу нәрсә? Ул ничек кычкыра?”

Материал: ат, кәҗә, тавык, каз, карга сурәтләнгән картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага ат (кәҗә, тавык, каз, карга) төшерелгән картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: - Бу нәрсә? (Ат). Ат ничек кешни? (Их-ха-ха). - Бу нәрсә? (Кәҗә). Кәҗә ничек кычкыра? (Ме-е-е). - Бу нәрсә? (Тавык). Тавык ничек кыткылдый? (Кыт-кыт). - Бу нәрсә? (Каз). Каз ничек каңгылдый? (Ка-ка-ка). - Бу нәрсә? (Карга). Карга ничек каркылдый ? (Кар-кар).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала 1-2 биремне генә үти ала.

**2 балл** – бала биремнәрне тәрбияче ярдәме белән башкара, аның артыннан кабатлый.
**3 балл** – бала биремнәрне теләп башкара. Аваз ияртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә.

**4. Бәйләнешле сөйләм**
1). Сюжетлы картина буенча әңгәмә
Материал: кар бабай ясаучы балалар сурәтләнгән сюжетлы картинка.
Диагностик биремнең эчтәлеге:
- Карагыз әле, Йомшаккай бик матур бер картинка ясаган. – Бу картинкада кем ясалган? – Балалар нәрсә эшлиләр? - Картинка сиңа ошыймы?
2). “Камыр малай” әкиятен сәхнәләштерү.
Тәрбияче өстәл театры фигуралары куллана, балаларга сәхнәләштерүдә катнашырга тәкъдим ясый.

**Бәяләү критерийлары**
**1 балл** – бала сорауларга ишарәләр яки бер сүз белән генә җавап бирә. Әкиятне сәхнәләштерүдә авырлыклар кичерә. Тәрбияче артыннан аерым сүзләрне генә кабатлый.
Тәрбияче: - Балалар, камыр малайны пешергәннәр әби белән
Бала: Бабай.
Тәрбияче: - Камыр малайны тәрәзә төбенә
Бала: Куйганнар.
Тәрбияче: Камыр-курчак кипкәч, тәрәзәдән
Бала: Сикереп төшә.
Тәрбияче: Камыр малай йөгереп китә, йөгерә-йөгерә урманга
Бала: Җитә.
**2 балл** – бала җавап биргәндә 2-3 сүздән торган гади җөмләләргә өстенлек бирә. Тәрбияче ярдәм иткәндә таныш әкиятне сәхнәләштерүдә катнаша.
Тәрбияче: - Балалар, камыр малайны пешергәннәр
Бала: әби белән бабай.
Тәрбияче: - Камыр малайны
Бала: Тәрәзә төбенә куйганнар.
Тәрбияче: Камыр-курчак кипкәч,

Бала: Тәрәзәдән сикереп төшә.

Тәрбияче: Камыр малай йөгереп китә, йөгерә-йөгерә

Бала: Урманга җитә.

**3 балл** – бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди? кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үзенең инициативасы яки тәрбияченең үтенече буенча картинада сурәтләнгәнне сөйли ала. Әкиятнең эчтәлеген сөйләгәндә эзлеклелекне саклап сәхнәләштерүдә теләп катнаша.

**Югары дәрәҗә** - 10-12 балл., **Уртача дәрәҗә** - 6-9 балл., **Түбән дәрәҗә** - 3-5 балл.

**Рус төркемендә тәрбияләнүче татар балаларының ана телен үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү (беренче кечкенәләр төркеме)**

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Сүз байлыгы<br>Бу кем? Бу нәрсә? | Сөйләмнең грамматик ягы | | Уеннарда катнашу | | Аваз культурасы<br>Ул ничек кычкыра? | Бәйләнешле сөйләм | | Баллар | | Дәрәҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Бирем үтәү | Нинди? | | | | Үзең турында сөйләү (син кем?) | Рәсем буенча әңгәмә (сорау-җавап) | | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | **1 балл**<br>**2 балл**<br>**Нәтиҗәләрне бәяләү** | | | | | | | | | | |
| **Югары дәрәҗә**<br>17-21 балл | | | | | | | **Бала сөйләмдә актив, аралаша.** | | | | | |
| **Уртача дәрәҗә**<br>12-16 балл | | | | | | | **Аңлый, тәрбияче ярдәмендә аралаша.** | | | | | |
| **Уртачадан түбән дәрәҗә**<br>1-11 балл | | | | | | | **Аңлый, сөйләшми.** | | | | | |

**Рус төркемендә тәрбияләнүче татар балаларының ана телен үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү**
**(икенче кечкенәләр төркеме)**

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Сүз байлыгы<br><br>Бу кем? Бу нәрсә? | Сөйләмнең грамматик ягы | | Уеннарда катнашу | | Аваз культурасы<br><br>Минем кебек әйт | Бәйләнешле сөйләм | | Баллар | Дәрәҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Нәрсә эшли? | Нинди? | | | | Үзең турында сөйләү (син кем?) | Рәсем буенча әңгәмә (сорау-җавап) | | |
| | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |
| | Нәтиҗәләрне бәяләү | | | | | | | | | | |

| | | |
|---|---|---|
| Югары дәрәҗә<br>17-21 балл | | Бала сөйләмдә актив, аралаша. |
| Уртача дәрәҗә<br>12-16 балл | | Аңлый, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә<br>1-11 балл | | Аңлый, сөйләшми. |

**2.4. Ата- аналар белән эш**

- Беренче һәм икенче кечкенәләр төркеменә яңа килгән татар милләтеннән булган балаларның ата – аналары белән анкета үткәрү.
- Ата – аналар җыелышында чыгышлар ясау.
- Консультацияләр үткәрү.
- Ачык ишекләр көне үткәрү.
- Балалар бакчасының сайтында информацияләрне яңартып тору.
- “Туган телдә сөйләшәбез” папкаларындагы информацияләрне яңартып тору.
- Индивидуаль консультацияләр бирү, әңгәмәләр үткәрү.
- Ата- аналарның, балаларның рәсемнәре күргәзмәсе үткәрү.

**Педагогик коллектив белән эш**

- Педагоглар өчен татар теленә өйрәтү курслары үткәрү.
- Педагогик киңәшмәләрдә чыгышлар ясау.
- Консультацияләр бирү.
- Төркем тәрбиячеләре һәм белгечләр белән берлектә бәйгеләр үткәрү.
- Ачык ишекләр көнендә эшчәнлек күрсәтү.

**Балалар белән эш**

- Программа материалларын үзләштерү дәрәҗәсенең мониторингы
- Сәләтле балаларны төрле бәйгеләрдә, бәйрәмнәрдә катнаштыру
- Татар халкының, Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның милли йолалары, гореф гадәтләре белән танышу, бәйрәмнәр, кичәләр. Төрле чаралар оештыру
- Балаларны Г.Тукай әсәрләре белән таныштыруның системалы эшен дәвам итү (мультфильмнар карау, балаларның рәсемнәре...)
- Татар язучылары һәм Татарстан Республикасында яшәүче башка халыкларның әсәрләре һәм караган мультфильмнар буенча балалар белән күмәк эш әзерләү.
- Укыту эшчәнлеге дәверендә гаилә клубы төркемнәрендә, гаиләдә балалар белән региональ компонентларны күз алдында тотып укыту- тәрбия процессын оештыру.Ачык ишекләр көне.

## 1. Оештыру бүлеге

### 3.1.Татар теле кабинетында предметлы-үстерүче тирәлекне оештыру үзенчәлекләре

Татар телендә дөрес сөйләшергә өйрәтү өчен, балаларны кызыксындыра алырлык аралашу даирәсе булдыру, сюжетлы уеннар оештыру, гомүмән, баланың актив сөйләмен үстерү зарур. Тәрбиячегә татар телен өйрәнүче мәктәпкәчә яшьтәге балаларның телне ясалма тудырылган тел мохитендә үзләштерүләрен онытмаска кирәк. Татар телен өйрәтү шөгыльләре өчен балалар бакчасында махсус бүлмә бар. Бу бүлмәдә РФ һәм ТР дәүләт символлары, туган шәһәр, башкаладагы истәлекле урыннарның фотографияләре, татар, рус, чуваш һ.б. халыкларның декоратив-гамәли сәнгать үрнәкләре сүрәтләнгән альбомнар, үстерешле уеннар, татар халык әкиятләренең геройлары. Татар теле бүлмәсендәге уенчыклар зур, ялтыравыклы, балаларны җәлеп итәрлек, уенчыклар аларның буе җитәрлек шкафларда урнаштырылган.

| |
|---|
| 1. РФ и ТР символикасы (герб, флаг). РФ и ТР президентларының фотографияләре. |
| 2.Татар, рус, мари, удмурт, чуваш милли киеменнән курчаклар. |
| 3.ТР башкаласы Казан шәһәре турында информацион һәм күрсәтмәматериал (альбомнар, китаплар, открыткалар, иллюстрацияләр). |
| 4. ТР турында информацион һәм күрсәтмә материал (шәһәрләр, аларның истәлекле урыннары, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы). |
| 5.Татарстан, Россия, Башкортостан, Чувашия, Удмуртия, Мари-Эл, Мордовия турында информацион һәм күрсәтмә материал (папкалар, дидактик, хәрәкәтле уеннар). |
| 6.Татар язучыларының һәм шагыйрьләренең портретлары һәм әсәрләре Татар халык әкиятләре. |
| 7.Татар милли орнаментларының үрнәкләре (7 элемент):лалә, яфрак, кыңгырау, канәфер чәчәге, өч яфрак, чалмабаш, гөлҗимеш.Дидактикуеннар:1. «Бизәкне төзе»; 2. «Парын тап»;3. «Тап һәм ата»;4. «Киемне бизә» |
| 8. Татар милли орнаментлары белән таныштыру өчен |
| 9. Яшелчә һәм җиләк-җимеш муляжлары. |
| 12. Уенчыклар: йорт хайваннары, кыргый хайваннар, савыт-саба, җиһаз, предметлы уенчыклар. |
| 11.УМК буенча дидактик уеннар:«Бер һәм күп», «Кем нәрсә эшли», «Курчакны киендер», «Яшелчәләр», «Жиләк-жимешләр», «Кечкенә рәсемнәрне таратып сал», “Кәрзиндә нәрсә бар?”, “Төсе буенча тап”, “Бу кем?”, |
| 13.Журналлар: «Мәгариф», «Салават күпере», ”Көмеш кынгырау, «Кучтәнәч». |
| 14.Документация: портфолио, папкалар, учет дәфтәрләре, диагностика һәм аның өчен инструментарий, анкеталар, планнар: календарьһәм коплекслы-тематик планнар, УМКны тормышка ашыру, рус телле тәрбиячеләрне татар теленә өйрәтү. Уеннар тупланган папкалар: хәрәкәтле уеннар, халык,бармак уеннары, |

**3.2. Эш көне бүленеше**

| №<br>п/п | Эш төре | Вакыт |
|---|---|---|
| 1.<br>2.<br>3.<br>4.<br>5.<br>6.<br>7.<br>8.<br>9.<br>10.<br>11. | Диагностика ясау.<br>Эшчәнлекләр үткәрү.<br>Балалар белән бәйрәмнәр оештыру.<br>Тәрбиячеләр, әти-әниләргә чыгышлар ясау.<br>Еллык бәйрәмнәрдә катнашу.<br>Халык бәйрәмнәрендә катнашу.<br>Әти-әниләргә төркемнәрдә “Татарча сөйләшәбез” почмагын тулыландыру.<br>Тәрбиячеләргә, әти-әниләргә холда стендта мәгълүматлар бирү.<br>Мини –музейны баету.<br>Шәһәр, район, бакча куләмендә оештырылган методик киңәшмәләрдә катнашу.<br>Китаплар белән “Буккросинг”ны тулыландыру. | Сентябрь – май |

## 3.3.Кулланылган әдәбият.


1. Ал кирәк,гөл кирәк (методик кулланма). Р. Ягъфәров.- Казан. 1995.
2. Балачак аланы (хрестоматия). К.В.Закирова. - Казан. 2011.
3. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы. М.А.Васильева, В.В. Гербова, Т.С. Комарова. - Казан Мәскәү.2006.
4.Балалар бакчасында татарча сөйләм үстерү дәресләре (методик кулланма.) З.М. Зарипова, А.И.Касимова.- Казан 2010.
5. Белем бирү һәм тәрбия процессында милли төбәк компоненты(методик кулланма). З.М. Зарипова. - Яр Чаллы. 2000.
6. Балалар фольклоры. Н. Исәнбәт. - Казан. 1984.8. Балалар бакчасы (хрестоматия). Ф.Ю. Юсупов.- Казан. 2003.
7. Бал бабай. З.М.Зарипова, И.М. Хәмитов. - Яр Чаллы. 2000.
8. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү (программа). К.В.Закирова...- Казан 2009.
9. Балалар бакчаларында телдән сөйләмгә өйрәтүнең фәнни методик нигезләре (монография). М.Ф.Кашапова. - Казан. 2009.
10. Гөлбакча (хрестоматия). Ф.Ю. Юсупов... - Казан. 1990.
13. Диагностика речевого развития дошкольников. (3-7 лет). О.С.Ушакова, Е.М. Струнина. - Москва. 1999.
14.Иң матур сүз (хрестоматия). К.В.Закирова. - Казан. 2000.
15. Иң татлы тел-туган тел (методик кулланма). М.Ф.Кашапова. - Казан. 2004.
16. Көч һәм рух тамырлары (хрестоматия). К.В.Закирова, Р.А.Низамов.- Казан. 1998.
17. Кәҗә-мәкәрҗә (методик кулланма). Р. Ягъфәров.- Казан. 1994.
18. Методика развития речи детей. А. М. Бородич.- Москва. 1981.
19. Раушан көзге (хрестоматия). Р.Ш.Халикова.- Казан. 1993.
20.Татар халык уеннары. Р. Ягъфәров. - Казан. 2002.
21. Татар халык табышмаклары. “Идел-йорт” нәшрияте. - Яр Чаллы. 2000.
22. Уйный-уйный үсәбез (хрестоматия). К.В.Закирова. - Казан. 2005.
23. Уйныйк әле, балалар (методик ярдәмлек). М.Ф.Кашапова.- Казан. 2011.
24. Әхлак дәресләре (дәрес эшкәртмәләре). В. С. Казыйханов.- Яр Чаллы. 1997.
25. Әхлак белеме - (хрестоматия). В. С. Казыйханов. Яр Чаллы. 2000.
26. Әткәм-әнкәмнең теле (методик кулланма). К.В.Закирова, С.М.Гаффарова.- Казан. 1997.
27. Әдәп-матур гадәт. З.М.Зарипова. - Яр Чаллы. 2009.